**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ IX СЕССИЯСЕ**

**К А Р А Р № 43**

Мөслим авылы «26» август 2021 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы «Мөслим авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 августындагы 195 номерлы Мөслим муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 6 статьясының 14 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы «Мөслим авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының 2020 елның 28 августындагы 195 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. «Шәһәр төзелеше регламентлары» бүлегендә индивидуаль торак төзелеше өчен, шәхси ярдәмче хуҗалык (йорт янындагы җир кишәрлеге) алып бару һәм блокланган торак төзелеше өчен рөхсәт ителгән файдалану төре булган җир кишәрлегенең минималь күләмен 1000 кв.м. билгеләргә.

2. Әлеге карарны Интернет-мәгълүмат челтәрендәге Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мөслим муниципаль районы Советы рәисе урынбасары А.М. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе Р.Х. Муллин